
# «БЕРВАКЫТ МИН ЯТИМ БУЛМАВЫМА ҮКЕНДЕМ...»

11июнь, 2005 ел. N24



Халкыбыз гаҗәеп үзенчәлекле иҗат ияләре белән дан тота. Шундый иҗат әһелләренең берсе — **Хәмит ЛАТЫЙП.** Аны әле “кеше-оркестр” дип тә атыйлар. Нигәме? Чөнки ул бик тә киң кырлы рәссам: агачка уеп эшләү остасы, сынчы, пастель техникасында төрледән-төрле, өрҗаңа стильләр тудыручы, керамика, майлы буяу, графика һәм монументаль әсәрләр авторы. Өстәвенә — сүз рәссамы да ул — шагыйрь дә.

**Рәсемнең исе бармы?** Буяу исе килә, диярсез. Юк, буяу исе генә түгел, Хәмит Латыйпның сурәтләреннән дала кылганнары исе, *куе сөтле чәй исе, салкын кар катламын тишеп* чыккан умырзая чәчәге исе килә. Аның сурәтләрендә Шәрыкның илаһи вә нәзберек төсләре беренче көнне бик тә кырыс авангардлык чалымнары белән бергә, ничектер табигый рәвештә үрелеп куела. Аларны күңеләңә сеңдерү өчен “Сак-Сок” бәетен дә, “Иске кара урман”, “Гөлҗамал” җырларын да сеңдергән булуың, татар булып тууың кирәк!

**Марат ЗАКИР.**

Хәмит ЛАТЫЙП

## Кырмыскала

“Кырмыскала” —
Дип атала
Шул урманда
Матур кала.
Эшләп ята
(бик күп анда),
Яшәп ята
Кырмыскалар —
Тырыш бар да.
Кырмыскала —
Матур кала,
Мәшһүр кала!
Бик күп катлы,
Биек башлы
Эшләп ята
Кырмыскала!
Эшчән алар —
Кырмыскалар!
Кырмыскала —
Бик зур кала.
Анда бара,
Монда бара:
Тырыш алар,
Төзи алар
Бик зур кала —
Кырмыскала.

## Өй иясе

Өчиледә — өч идән,
Чыгып килә кич өйдән
(Көчкә ди килгән көйдән),
Үзе өч бишмәт кигән;
Буе чүт озын чөйдән,
Үзе чыга ди өйдән.

Өчиледә — өч идән.
Кем чыгып йөргән өйдән?
Өстенә бишмәт кигән.
Көчкә ди килгән көйдән,
Буе чүт озын чөйдән,
Чыгып килә ди өйдән.

Өчиледә — өч идән.
“Килә-килә” — ди! белгән! —
“Өй иясе” — ди! йөргән.
Менә аны кем күргән? —
Буе чүт озын чөйдән,
Үзе чыга ди өйдән.





